**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге составына керүче Кече Шилнә авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

26 октябрь, 2020 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 25 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Кече Шилнә авылында юлларны ремонтлау;
2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;
3) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау
4) тротуарны төзекләндерү
5) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)
6) су башняларын, скважиналарны ремонтлау һәм төзекләндерү
7) коймаларны төзекләндерү

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **1236** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **842** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы **780** кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы **62** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 1500 (бер мең биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) Кече Шилнә авылында юлларны ремонтлау;

2) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;

3) урам утларын урнаштыру һәм ремонтлау

4) тротуарны төзекләндерү

5) су челтәрләрен ремонтлау (ремонт эшләре, проект эшләре)

6) су башняларын, скважиналарны ремонтлау һәм төзекләндерү

7) коймаларны төзекләндерү мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Кече Шилнә авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кече Шилнә авыл җирлеге Башлыгы А.Г.Даутов